ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ "ИННОПОЛИС ШӘҺӘРЕ" МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ГРАЖДАННАРЫНЫҢ УТЫЗ ИКЕНЧЕ ҖЫЕНЫ

КАРАР № 1

«31» октябре 2018 ел Иннополис ш.

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
“Иннополис шәһәре” муниципаль берәмлегене
Уставын кабул итү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 44 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 7 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 07 октябрендәге 75-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге уставының 93 - 95 статьялары нигезендә, 2018 елның 27 сентябрендәге гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен исәпкә алып,

«Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге гражданнар җыены
КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставын 1 нче кушымта нигезендә кабул итәргә.

2. «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге уставы турында» 2017 елның 28 апрелендәге 2 номерлы Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге гражданнарының егерме сигезенче җыены һәм Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» 2018 елның 19 апрелендәге 1 номерлы Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы гражданнары җыенының карары Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы үз көченә кергән көннән үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны дәүләт теркәвенә алу өчен законнарда билгеләнгән тәртиптә теркәү органына җибәрергә.

4. Әлеге карар Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) мизгелдән Югары Ослан муниципаль районының Интернет челтәрендәге мәгълүмат сайтында (http://verhniy-uslon.tatarstan.ru/) һәм Иннополис шәһәренең дәүләт теркәве узганнан соң махсус мәгълүмат стендларында үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен үзем контрольдә тотам.

Рәислек итүче,
Иннополис шәһәре Мэры Р.Р. Шагалеев